**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Кирлегәч авыл җирлеге**
**Кирлегәч авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән: студентлардан тыш, 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Кирлегәч авылында Ленин, Кустарная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау буенча эш (вак таш җәю, смета нигезендә килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кирлегәч авылы, авыл мәдәният йорты - Советская 33А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кирлегәч авыл җирлеге башлыгы: С.Р.Сәлахова

ИНН 1625000373
КПП 164901001